РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2021 елның 1 июле** **Чистай шәһәре** **№8/4**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районының «Чистай
шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир
биләмәләреннән файдалану һәм
төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр
кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мәгълүмат тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2021 елның 21 апрелендә уздырылган ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Чистай шәһәре Советының 2012 елның 19 декабрендәге 18/7 номерлы (Чистай шәһәре Советының 2016 елның 30 июнендәге 7/1 номерлы, 25.08.2016 ел № 8/4, 27.04.2017 ел № 14/5, 28.09.2017 ел 18/4, 02.11.2017 ел №19/2, 14.12.2017 ел №20/13, 21.03.2018 ел №23/5, 29.08.2018 ел №27/1, 24.10.2018 ел №28/5, 25.12.2018 ел №30/12, 28.02.2019 ел №32/1, 30.04.2019 ел №34/6, 11.06.2019 ел №35/4, 04.09.2019 ел №37/3, 27.11.2019 ел № 41/4, 11.02.2020 ел № 45/5, 13.05.2020 ел № 46/8, 16.07.2020 ел №49/2, 02.09.2020 ел № 50/8, 28.10.2020 ел № 3/4, 15.12.2020 ел № 4/9, 09.02.2021 ел № 6/3, 28.04.2021 ел № 7/7 карарлары редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең Чистай шәһәре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- СХ-2 «Авыл хуҗалыгы җитештерүе объектлары урнаштыру зонасы» территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, В.Ногин ур., 97-нче йорт чикләрендәге территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:080103:3 булган, 4026,00 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген Д-3 «Мәгариф объектларын һәм фәнни комплексларны урнаштыру зонасы» зонасына кертү өлешендә (1 нче кушымта);

- СН-4 «Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы» территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Курченко ур. чикләрендәге территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54 130103:508 булган, 15050,00 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген ПК-3 «IV-V класслы куркыныч җитештерү-коммуналь объектлар зонасы» зонасына кертү өлешендә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов


Чистай шәһәре Советының
2021 елның 1 июлендәге
8/4 номерлы карарына
1 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:





Кертелә торган үзгәрешләр:



Чистай шәһәре Советының
2021 елның 1 июлендәге
8/4 номерлы карарына
2 нче кушымта

Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы

Гамәлдәге нигезләмә:




Кертелә торган үзгәрешләр:

